СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.11.2021 с. Верхний Услон № 14-98

Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлегенең
Киров исемендәге поселогы территориясендә гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Уставның 24 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Киров исемендәге торак пунктының бер өлешендә яшәүчеләрнең инициативасын карап,

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Советы Башлыгы
карар итте:

1. 2021 нче елның 4 нче декабрена 9.00 сәгатьтә Югары Ослан муниципаль районының Киров исемендәге поселогы территориясендә гражданнар җыенын үткәрергә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Киров исемендәге бистәсе территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме»

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Киров мәдәният йортында гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Киров исемендәге поселок, Центральная ур., 15 йорт.

4. Җыенны Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль майоны Башлыгы М.Г.Зиатдинов